**Министерство образования и науки Республики Татарстан**

**Нижнекамский муниципальный район**

**МБОУ «Гимназия №2» имени Баки Урманче**

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат: 2AC06D00DFB1188542264373AABE4F3B
Владелец: Гаязова Айгуль Нильсоновна
Действителен: с 02.09.2024 до 02.12.2025

Директор
Гаязова А.Н.
Приказ № 450 от 29.08.2024 г.

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**по внеурочной деятельности**

**«Туган телем – иркә гөлем»**

для обучающихся 1 классов

## Курсның эчтәлеге.

Программа 1 нче сыйныфта сыйфатлы белем бирүне коммуникатив, лингвистик, этнокультура өлкәсенә караган компетенцияләргә нигезләп, аларны бер-берсе белән тыгыз бәйләп алып баруны күз уңында тота. Ул федераль дәүләт белем стандартлары таләпләренә туры китереп төзелгән. Шуңа күрә татар телен рус теле белән чагыштырып бару, рус теленең үзенчәлекләрен яхшы сиземләү, ике телгә хас булган охшаш һәм аермалы якларны даими рәвештә күрсәтү – болар барысы да игътибар үзәгендә тора.

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш». Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата. Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирү программасы укытуның эчтәлеген, күләмен, эзлеклелеген билгели. Теоретик материал фәннилек, системалылык, дәвамчанлык, функциональ-семантик, культурологик, үстерешле укыту, шәхескә юнәлешле укыту принципларын салып бирә. Программа башлангыч сыйныфта сыйфатлы белем бирүне коммуникактив, лингвистик, этнокультура өлкәсенә караган компетенцияләргә нигезләп, аларны бер-берсе белән тыгыз бәйләп алып баруны күз уңаенда тота.

Коммуникатив компетенция

Сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре ( тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм) буенча укучыларда күнекмәләр булдырыла. Беренче баскычта укучылар укылган яки тыңланган текстның эчтәлегенә төшенә, темасын билгели ала, текст буенча әңгәмә үткәрә ала, гади план төзеп, телнең орфографик һәм орфоэпик нормаларын саклап, телдән яки язмача эчтәлеген җиткерә, тексттагы җөмләләрне синтагмаларга бүлеп, сөйләм яңалыгын белдергән кисәкләргә логик басым ясап, сәнгатьле итеп укый белә, текстка үз мөнәсәбәтен белдерә һәм аны дәлилли. Тәкъдим ителгән темалар (үзе турында, гаилә, туган ил, табигать, хезмәт, балалар тормышы, сәламәтлек, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр) буенча диалогик һәм монологик сөйләм оештырырга сәләтле. Дөрес һәм матур язу күнекмәләрен үзләштерә. Төрле типтагы язма эшләр (диктант, өйрәнү тибындагы изложение, сочинение) башкара. Көндәлек аралашуга бәйле сөйләм этикеты үрнәкләрен дөрес файдалана.

**Шәхси нәтиҗәләр**

Укучылар өйрәнәчәк:

- туган республикага, туган илгә, халкына, ил тарихына карата гражданлык нигезләрен, үз милләтен яратырга, татар булуы белән горурланырга;
- табигать, халык, культура, дин төрлелеген берләштергән дөньяга социаль караштa булырга;
- башка халыкларның культурасына, тарихына хөрмәтле карарга, башкалар фикеренә карата түземлелекле булырга;

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:

- башкалар хисен аңлау, кайгырта белү, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, әхлакый хисләре булдырырга;
- дуслары, олылар белән хезмәттәшлек итергә, конфликтлы ситуацияләрне булдырмыйча, алардан чыгу юлларын таба белергә;
- - куркынычсыз һәм сәламәт яшәү рәвешен белергә, төрле тормыш ситуацияләренә һәм әдәби әсәрләрдәге геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирергә;
- иҗади хезмәткә, эшнең нәтиҗәсенә мотивация булдырырга, материаль һәм рухи байлыкларга сак карашлы булырга.

**Предметара нәтиҗәләр**

Танып белү универсаль уку гамәлләре

Укучылар өйрәнәчәк:

- мөһим бәйләнешләрне аерып чыгару нигезендә кагыйдә формалаштырырга;
- күнегүләрне мөстәкыйл эшләү алымнарын үзләштерергә;
- тәкъдим ителгән план буенча телдән аңлатырга;
- материаль объект, таблица, рәсем, схемалар, сүзлекләр кулланырга;
- бирелгән алгоритм буенча күнегүләр башкарырга;
- фикерләүдә логик чылбыр төзергә;
- уку мәсьәләләрен модельләштерүдә билгеләр (символлар) кулланырга.
- укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:
- интернетны кулланып, мәгълүмат эзләргә;
- мөстәкыйль рәвештә нигезләмә һәм критерийлар сайлап, чагыштыру, сериация һәм классификация башкарырга;
- сәбәпле-нәтиҗәле мөнәсәбәтләр урнаштыруны үз эченә алган логик хикәяләү төзергә.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

- партадаш күрше белән яисә төркемдә хезмәттәшлек итәргә;
- нинди дә булса предмет яисә объектка төрле карашлар булу мөмкинлеген аңларга;
- килешергә һәм уртак эшчәнлектә гомуми чишелешкә килергә;
- сораулар формалаштырырга.
- укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:
- сораулар ярдәмендә партнердан өстәмә мәгълүмат алырга;
- монолог төзергә.

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**

Укучылар өйрәнәчәк:

- таблица буенча кагыйдәнең дөреслеген тикшерегә;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башларга һәм тәмамларга;
- кагыйдә, инструкцияләрне истә тотарга һәм шуларга ияреп гамәлләр кылырга;
- максатка кагылышсыз гамәлләрдән тыелырга;
- сәбәпле-нәтиҗәле бәйләнешләр урнаштырырга.
- укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:
- партадаш күршең белән хезмәттәшлектә яңа уку мәсьәләләрен куярга;
- уку эшчәнлегенең үзең өчен әһәмиятен, мәгънәсен һәм сарыф ителгән вакытны, көчне бәяләргә;
- ирешеләчәк нәтиҗәне алдан фаразларга;
- яңа уку мәсьәләсен чишүгә керешкәнче үз мөмкинлекләреңне мөстәкыйль бәяләргә.

**Предмет нәтиҗәләре**

Укучылар өйрәнергә мөмкинлек алачак:

- темасыннан яки төп фикереннән чыгып, текстка исем кую.
- хикәяләү, тасвирлау һәм фикер йөртү характерындагы текстларны аера белү.
- шәхси тәҗрибәгә, сюжетлы картинага таянып (алдан әзерлек белән).
- фикер йөртү характерындагы җавап төзеп әйтү.

**Календарь-тематик планлаштыру**

| № | Тема | Сәгатьләр саны | Вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План буенча | Фактта |
| 1. | Аралашу әдәбе. | 1 | | |
| 2. | Ягымлы сүзләр. | 2 | | |
| 3. | Туган ягым табигате. | 2 | | |
| 4. | Туган ягым төбәге-Түбән Кама. | 2 | | |
| 5. | Безнең гаилә. | 2 | | |
| 6. | Җиләк җимешләре. | 1 | | |
| 7. | Икмәк-яшәү терәге. | 2 | | |
| 8. | Йорт хайваннары һәм кошлар. | 2 | | |
| 9. | Кыргый хайваннары. | 2 | | |
| 10. | Тылсымлы сүзләр. | 2 | | |
| 11. | Һөнәрләр. | 2 | | |
| 12. | Бәйләнешле сөйләм. Рәсем буенча хикәя төзү. | 1 | | |
| 13. | Г.Тукай иҗаты. | 1 | | |
| 14. | Г.Тукай "Су анасы". | 2 | | |
| 15. | Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы. | 2 | | |
| 16. | Иҗади биремле күнегүләр, тест эшләү. | 1 | | |
| 17. | Халык авыз иҗаты. | 2 | | |
| 18. | Тел турында мәкальләр һәм әйтемнәр. "Мәкальне дәвам ит" уены. | 2 | | |
| 19. | Тизәйткечләрнең яки тел бутагычларның тормыштагы роле. | 2 | | |
| 20. | Табышмак әйтәм-тап. | 2 | | |
| 21. | Мин һәм минем сәламәтлегем. | 2 | | |
| 22. | Нәрсә ул яхшы һәм нәрсә ул начар. | 2 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 23. | Мин дөньяның бер кешесе. | 2 | | |
| 24. | Татар исемнәре иленә сәяхәт. | 2 | | |
| 25. | Ел эчендә дүрт  фасыл, дүртесе дә бик асыл. | 2 | | |
| 26. | Татар халкының милли киемнәре. | 2 | | |
| 27. | Татар халкының милли ризыклары. | 2 | | |
| 28. | Татар халкының милли бәйрәмнәре. | 2 | | |
| 29. | Татар халык уеннары. | 2 | | |
| 30. | Татар халкының гореф - гадәтләре. | 2 | | |
| 31. | Татар телендә башваткычлар. | 2 | | |
| 32. | Татар тарихында беренче китаплар. Китап ясау. | 2 | | |
| 33. | Әкият иленә сәяхәт. | 2 | | |
| 34. | Әкият сәхнәләштерү. | 2 | | |
| 35. | Кроссвордлар тезү. | 2 | | |
| 36. | Уен дәрес. | 1 | | |